Тукай муниципаль районы
Күзкәй авыл җирлеге
Күзкәй авылы
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«25» октябрь 2024 ел № 2

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Күзкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Советы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында 2019 елның 05 ноябрендәге 10/1 номерлы карары нигезендә Күзкәй авылы җирлеге Күзкәй авылы гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. «Күзкәй авыл җирлегенең Күзкәй авылы территориясендә 2025 елда балигъ булган, Күзкәй авыл җирлегенең Күзкәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә, I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә, аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (киртә өчен материаллар сатып алу һәм урнаштыру).

2. Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Күзкәй авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Күзкәй авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күзкәй авыл җирлеге Башлыгы Э.Р. Гараев